**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# 2024 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы комиссиянең 2024 елда чыгарма тәртибендә дүрт Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген тапшыру турындагы тәкъдимен караганнан соң, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Вайнер Борис Гиршевичка – балалар шигърияten, прозасын һәм драматургиясен үстерүгә, яшь укучыларга әхлакый-эстетик тәрбия бирүгә, татар балалар әдәбияты һәм фольклорының иң яхшы әсәрләрен тәрҗемә итүгә һәм популярлаштыруга, Татарстанның яшь талантларына иҗади ярдәм күрсәтүгә күп еллар дәвамында керткән өлеше өчен;

2) Җәмитов Кадим Җәлил улына – татар мәдәниятенең күренекле тарихи эшлеклеләренә багышланган скульптура портретлары һәм сыннар сериясен иҗат иткәне өчен;

3) Мөдәррисова (Тәминдарова) Миләүшә Әмир кызына – Татарстанның татар хор культурасын үстерүгә, танытуы һәм саклавы, «Татар хор музыкасы антологиясе» хезмәте өчен;

4) Харрасов Ләис Мәүлит улына (Ләис Зөлкарнәйгә) – «Узганны кабатлау» китабы өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 25 апрель
№ 299